ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «03» мартыннан № 34

## 2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе нигезләмәсен һәм составын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 49 номерлы карары, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының 2026 елның 12 февралендәге 49 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен, керемнең чик күрсәткечләрен билгеләүне исәпләү нигезендә 2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы күләмнәренең иң чик күрсәткечләрен әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 788 328

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 576 656

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 364 984 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 153 312 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 941 640 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 4 729 968 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 518 296 сум;

1.1.8. сигез кешедән торган гаилә өчен - 6 306 624 сум.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 31133,26 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 31133,26 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 31133,26 сум.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясенә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларына таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.Р.Камалетдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «03» мартындагы
34 номерлы карарына
кушымта

2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен исәпләү

1. СЖ = НП x РС x РПС, биредә

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РПС - торак мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе – 43796 Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең 2025 елның 04 июлендәге 150 номерлы хатындагы уртача күрсәткеч кулланылды

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 18 x 1 x 43547 = 788 326 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 2 x 43547 = 1 576 656 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 3 x 43547 = 2 364 984 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 4 x 43547 = 3 153 312 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 5 x 43547 = 3 941 640 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 6 x 43547 = 4 729 968 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 7 x 43547 = 5 518 296 сум

д) сигез кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 18 x 8 x 43547 = 6 306 624 сум

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС/(1-(1 + ПС)^{-КП})/(0,3 \times РС)$, биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айда кредит буенча процент ставкасы (елына 25 % яки 20 % беренче кертем шарты белән аена 25 %) - 0,02;

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) («Татарстан Республикасы ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматы нигезендә, кредит бирү срогы 20 ел яисә 240 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = $0,7 \times 783846 \times 0,02 / (1 - (1 + 0,02)^{-240}) / (0,3 \times 1) = 31133,26$ сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = $0,7 \times 1567692 \times 0,02 / (1-(1 + 0,02)^{-240}) / (0,3 \times 2) = 31133,26$ сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД = $0,7 \times 2351538 \times 0,02 / (1-(1 + 0,02)^{-240}) / (0,3 \times 3) = 31133,26$ сум